**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.10.2018 № 861

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 2 июнендәге “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчалары) балаларны исәпкә кую һәм теркәү” муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентны яңа реадакциядә раслау турында” 275нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 2 июнендәге 275нче номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм теркәү” муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентнына (алга таба - регламент) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) регламентның V бүлекнең 5.1 пунктына 8, 9 пунктчасыларын өстәргә:

“8) муниципаль хезмәт курсәтү нәтиҗәләре буенча документлар тапшыру срогын яки тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт курсәтүен туктату, әгәр туктату сәбәпләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актлары белән каралмаган булса.”;

2) регламентның V бүлекнең 5.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.8. Шикаять карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шулай ук кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, «Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасына гариза керткәндә җибәрелгән хаталарны төзәтү, Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан республикасы норматив-хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган түләүләрне кире кайтару формаларында;

2) шикаять канәгатьләндерелми.”.

2. Әлеге карарны мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына Е.В. Сороковнинага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы М.Х. Хәбибуллова